РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«10 октября 2022г.

с. Тюлячи

№ 196

Гражданнарны Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакыруга бәйле рәвештә мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы мәгариф оешмаларында эшчәнлекне җайга салу турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар гаиләләрен Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» нә (Карпова Н.В.), хәрби комиссариатның мәгариф оешмасында тәрбияләнүченең гаилә әгъзасын Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакыру турындагы белешмәсе нигезендә, 1 пунктта китерелгән ташламаны күрсәтергә.

3. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) Теләче муниципаль районы мәгариф оешмаларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләреннән тәрбияләнүчеләрне тотуны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 10 октябреннән 2022 елның 31 декабренә кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин